Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«11» ноябрь 2020 ел № 5

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 9 ноябрендә, 10 ноябрендә, 11 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Гайтән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча торучы балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Гәйтән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Гәйтән авылында урамнарны яктырту системасы җиһазларын ремонтлау, яктырткычларны алыштыру һәм урнаштыру.

Гайтанкино торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

- Гайтанкино торак пунктында парк территориясен киртәләү өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 240 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 156 кеше катнашты.

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 132 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 24 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Гайтән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча торучы балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Гәйтән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Гәйтән авылында урамнарны яктырту системасы җиһазларын ремонтлау, яктырткычларны алыштыру һәм урнаштыру.

Гайтанкино торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

- Гайтанкино торак пунктында парк территориясен киртәләү өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева